**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Ләшәү Тамак авыл җирлегенең Сарайлы авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**2025 ел, 26 ноябрь** **№1**

2025 елның 20 мартындагы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 маддәсе, 28.07.2004 №45-ТРЗ Татарстан Республикасы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы законының 35 статьясы нигезендә, Сарман муниципаль районының Ләшәү Тамак авыл җирлеге Уставының 18.1 маддәсенә таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Ләшәү Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карар кабул итте: 2025 елның 26 ноябрендә 11.00 сәгатьтә үткәрелгән гражданнар җыенының «2026 елда 500 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләшәү Тамак авыл җирлеге Сарайлы авылы территориясендә I төркем инвалидлардан; ялгыз,өлкән булган затлардан; Украина территориясендә хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләренә; вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме:

1) Сарайлы авылы, Космонавтлар урамы, авыл эчендәге юлларны ремонтлау (таш ташу);
2) Сарайлы авылында "Беларус 82.1" тракторын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, һәм машина йөртүче хезмәте өчен түләү);
3) Сарайлы авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (материаллар сатып алу);
4) юл кырыен чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу, йөртүче хезмәтенә түләү);

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 208 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 116 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 116 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Ләшәү Тамак авыл жирлегенең Сарайлы авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.
2. «2026 елда 500 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләшәү Тамак авыл җирлеге территориясендә I төркем инвалидлардан; Украина территориясендә хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләренә;вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, ялгыз өлкән булган затлардан; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле

әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме » дигән сорау буенча карар кабул итәргә:
1) Сарайлы авылы, Космонавтлар урамы, авыл эчендәге юлларны ремонтлау (таш ташу);
2) Сарайлы авылында "Беларус 82.1" тракторын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, һәм машина йөртүче хезмәте өчен түләү);
3) Сарайлы авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (материаллар сатып алу);
4) юл кырыен чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу, йөртүче хезмәтенә түләү);

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Ләшәү Тамак авыл җирлегенең Сарайлы мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләшәү Тамак авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Ләшәү Тамак авыл җирлеге башлыгы,
Халык җыенында рәислек итүче

И.З.Хабибуллин